ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 27.02.2024 **КАРАР**

272

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 26 июлендәге 1144 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы карары нигезендә һәм Алабуга шәһәр прокуратурасы протестын караганнан соң, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 июлендәге 1044 номерлы карары белән расланган, адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 1.5 пунктындагы 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«планлаштырыла торган структура элементы - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы, яр буе), бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциячел булмаган берләшмәләре урнаштыру территорияләре»;

1.2. Регламентның 1.5 пунктындагы 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урам-юл челтәре элементы – урам, проспект, тыкрык, юл, мәйдан, бульвар, тупик (тыкрык), чыгу юлы, шоссе, аллея һәм башкалар»;

1.3. Регламентның 2 бүлегендәге 2.3. пунктының 2.3.2. пунктчасын

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2. Адресация объектына яңа адрес бирелгән очракта, аның адресын юкка чыгару турында карар, әлеге объектка яңа адресны бирү турында карар белән берләштерелергә мөмкин»;

1.4. Регламентның 2.4. пунктындагы 2.4.1. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- гаризаның кәгазьдәге формасы теркәлгән очракта, гариза кергән көннән соң кимендә 10 эш көне эчендә;

- гаризаны электрон документ формасында биргән очракта - гариза кергән көннән алып биш эш көне эчендә.

Муниципаль хезмәт алдан ук (проактив) режимда күрсәтелгән очракта – Регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән әүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгән көннән башлап өч эш көне эчендә.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазифасын вакытлыча башкаручы А.А. Томилин